ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредитлары бирү турындагы килешүләргә өстәмә килешүләр раслау хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 11 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм 2021 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» 2020 елның 15 октябрендәге 327-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 21 декабрендәге 2191 номерлы карары кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредитлары бирү турында төзелгән килешүләргә түбәндәге өстәмә килешүләрне расларга:

Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын өлешчә каплау өчен бюджет кредиты бирү турында 2016 елның 14 апрелендәге 01-01-06/06-72 номерлы, 2016 елның 22 июнендәге 01-01-06/06-100 номерлы, 2016 елның 29 июлендәге 01-01-06/06-128 номерлы килешүләргә 2020 елның 31 декабрендәге 6/6/6 номерлы өстәмә килешүне әлеге Законга 1 нче кушымта нигезендә;

Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын өлешчә каплау өчен бюджет кредиты бирү турында 2016 елның 14 апрелендәге 01-01-06/06-72 номерлы, 2016 елның 22 июнендәге 01-01-06/06-100 номерлы, 2016 елның 29 июлендәге 01-01-06/06-128 номерлы килешүләргә 2020 елның 31 декабрендәге 7/7/7 номерлы өстәмә килешүне әлеге Законга 2 нче кушымта нигезендә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 18 июнь
№ 38-ТРЗ

«Федераль бюджеттан
Татарстан Республикасы
бюджетына бюджет кредитлары бирү
турындагы килешүләргә
өстәмә килешүләр раслау хакында»
Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын өлешчә каплау өчен бюджет кредиты бирү турында 2016 елның 14 апрелендәге 01-01-06/06-72 номерлы, 2016 елның 22 июнендәге 01-01-06/06-100 номерлы, 2016 елның 29 июлендәге 01-01-06/06-128 номерлы килешүләргә

6/6/6 номерлы
# ӨСТӘМӘ КИЛЕШҮ

Мәскәү шәһәре 2020 елның 31 декабре

Россия Федерациясе Финанс министрлыгы исеменнән, алга таба «Кредитор» дип аталачак, Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 2014 елның 15 сентябрендәге 288 номерлы боерыгы (Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 2018 елның 5 июнендәге 712 номерлы боерыгы редакциясендә) нигезендә эш итүче Россия Федерациясе Финанс министрының беренче урынбасары Л.В. Горнин, бер яктан, һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты исеменнән, алга таба «Заемщик» дип аталачак, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасы Президентының 2017 елның 6 маендагы 273 номерлы күрсәтмәсе нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы Премьер-министры А.В. Песошин, икенче яктан, алга таба «Яклар» дип аталачак, «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм 2021 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» 2020 елның 15 октябрендәге 327-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясы һәм «2017 елда Россия Федерациясе субъектларының бюджет кредитлары буенча Россия Федерациясе алдындагы йөкләмәләренә (бурычларына) реструктуризация үткәрү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 13 декабрендәге 1531 номерлы карары («Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 21 декабрендәге 2191 номерлы карарында каралган үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба – Кагыйдәләр) нигезендә түбәндәгеләр турында әлеге өстәмә килешүне төзеделәр.

1. Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын өлешчә каплау өчен бюджет кредиты бирү турында 2016 елның 14 апрелендәге 01-01-06/06-72 номерлы, 2016 елның

22 июнендәге 01-01-06/06-100 номерлы, 2016 елның 29 июлендәге 01-01-06/06-128 номерлы килешүләргә 2020 елның 31 июлендәге 5/5/5 номерлы өстәмә килешүнең 5 пунктындагы «е» пунктчасына (алга таба – килешүләр, өстәмә килешү) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

беренче абзацтан соң түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«2021 елда бюджет кредитлары буенча бурычны каплау күләмен киметү нәтиҗәсендә азат ителә торган Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчаларын Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан каралган тәртиптә «2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына федераль бюджет турында» 2019 елның 2 декабрендәге 380-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 6 өлеше нигезендә билгеләнә торган яңа инвестиция проектларын гамәлгә ашыру максатларында Россия Федерациясе субъекты тарафыннан инфраструктура объектларына бюджет инвестицияләрен кертүгә, коронавирус инфекциясе таралуны профилактикалауга һәм аннан килгән зыяннарны бетерүгә бәйле чараларны финанс белән тәэмин итүгә, 2021 ел йомгаклары буенча Россия Федерациясе субъекты бюджетының салым һәм салым булмаган керемнәрен 2019 ел белән чагыштырганда киметүне компенсацияләүгә, шулай ук федераль проектларның максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итә торган региональ проектларны гамәлгә ашыруга бәйле Россия Федерациясе субъектларының чыгым йөкләмәләрен тәэмин итүгә юнәлдерү;»;

икенче абзацны өченче абзац дип санарга һәм аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2022 – 2024 елларда бюджет кредитлары буенча бурычны каплау күләмен киметү нәтиҗәсендә азат ителә торган Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчаларын Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан каралган тәртиптә «2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына федераль бюджет турында» 2019 елның 2 декабрендәге 380-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 6 өлеше нигезендә билгеләнә торган яңа инвестиция проектларын гамәлгә ашыру максатларында Россия Федерациясе субъекты тарафыннан инфраструктура объектларына бюджет инвестицияләрен кертүгә юнәлдерү.».

2. Килешүләрнең һәм әлеге өстәмә килешүнең анда кагылмаган һәм аларга каршы килми торган калган шартлары үзгәрми, һәм Яклар алар буенча үз йөкләмәләрен раслыйлар.

3. Әлеге өстәмә килешү һәр Як өчен берәр нөсхә итеп, бертигез юридик көчкә ия булган ике нөсхәдә 3 биттә төзелде.

**Урнашу урыны һәм адресы**

**Кредитор –** Россия Федерациясе Финанс министрлыгы, Ильинка урамы, 9, Мәскәү шәһәре, 109097.

**Заемщик –** Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Ирек мәйданы, 1, Казан шәһәре, 420060.

**Якларның имзалары**

**Кредитордан:**

Россия Федерациясе
Финанс министрының
беренче урынбасары

__________________Л.В. Горнин

**М.У.**

**Заемщиктан:**

Татарстан Республикасы
Премьер-министры

_________________А.В. Песошин

**М.У.**

«Федераль бюджеттан
Татарстан Республикасы
бюджетына бюджет кредитлары бирү
турындагы килешүләргә
өстәмә килешүләр раслау турында»
Татарстан Республикасы Законына
2 нче кушымта

Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын өлешчә каплау өчен бюджет кредиты бирү турында 2016 елның 14 апрелендәге 01-01-06/06-72 номерлы, 2016 елның 22 июнендәге 01-01-06/06-100 номерлы, 2016 елның 29 июлендәге 01-01-06/06-128 номерлы килешүләргә

7/7/7 номерлы
ӨСТӘМӘ КИЛЕШҮ

Мәскәү шәһәре 2020 елның 31 декабре

Россия Федерациясе Финанс министрлыгы исеменнән, алга таба «Кредитор» дип аталачак, Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 2014 елның 15 сентябрендәге 288 номерлы боерыгы (Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 2018 елның 5 июнендәге 712 номерлы боерыгы редакциясендә) нигезендә эш итүче Россия Федерациясе Финанс министрының беренче урынбасары Л.В. Горнин, бер яктан, һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты исеменнән, алга таба «Заемщик» дип аталачак, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасы Президентының 2017 елның 6 маендагы 273 номерлы күрсәтмәсе нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы Премьер-министры А.В. Песошин, икенче яктан, алга таба «Яклар» дип аталачак, «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм 2021 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» 2020 елның 15 октябрендәге 327-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясы һәм «2017 елда Россия Федерациясе субъектларының бюджет кредитлары буенча Россия Федерациясе алдындагы йөкләмәләренә (бурычларына) реструктуризация үткәрү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 13 декабрендәге 1531 номерлы карары («Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 21 декабрендәге 2191 номерлы карарында каралган үзгәрешләрне исәпкә алып) нигезендә түбәндәгеләр турында әлеге өстәмә килешүне төзеделәр.

1. Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын өлешчә каплау өчен бюджет кредиты бирү

турында 2016 елның 14 апрелендәге 01-01-06/06-72 номерлы, 2016 елның 22 июнендәге 01-01-06/06-100 номерлы, 2016 елның 29 июлендәге 01-01-06/06-128 номерлы килешүләргә 2020 елның 31 июлендәге 5/5/5 номерлы өстәмә килешүнең 6 пунктындагы бишенче абзацын (алга таба – килешүләр, өстәмә килешү) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Заемщик тарафыннан 2020 – 2024 еллар нәтиҗәләре буенча Кагыйдәләрнең 12 (1) пунктындагы «г» пунктчасында, шулай ук әлеге өстәмә килешүнең 5 пунктындагы «е» пунктчасында каралган йөкләмәләр үтәлмәгән очракта, Заемщик бюджет кредитлары буенча реструктуризация үткәрелгән бурычны һәм кичектереп түләгән өчен процентларны график нигезендә каплый, шулай ук Кредиторның күрсәтелгән йөкләмәләрнең вакытыннан алда үтәлмәве турындагы хәбәрнамәсе нигезендә, агымдагы елның 1 июленә кадәр, Кагыйдәләрнең 8 пункты нигезендә билгеләнгән бюджет кредитлары буенча реструктуризация үткәрелгән бурычны каплау күләме һәм Кагыйдәләрнең 12 пунктындагы беренче абзацы нигезендә билгеләнгән бюджет кредитлары буенча реструктуризация үткәрелгән бурычны каплау күләме арасындагы аерма буларак исәпләнгән бурычны хисап елында каплый.».

2. Килешүләрнең һәм әлеге өстәмә килешүнең анда кагылмаган һәм аларга каршы килми торган калган шартлары үзгәрми, һәм Яклар алар буенча үз йөкләмәләрен раслыйлар.

3. Әлеге өстәмә килешү һәр Як өчен берәр нөсхә итеп, бертигез юридик көчкә ия булган ике нөсхәдә 2 биттә төзелде.

**Урнашу урыны һәм адресы**

**Кредитор –** Россия Федерациясе Финанс министрлыгы, Ильинка урамы, 9, Мәскәү шәһәре, 109097.

**Заемщик –** Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Ирек мәйданы, 1, Казан шәһәре, 420060.

**Якларның имзалары**

| **Кредитордан:** | **Заемщиктан:** |
| --- | --- |
| Россия Федерациясе<br>Финанс министрының<br>беренче урынбасары | Татарстан Республикасы<br>Премьер-министры |
| ________________Л.В. Горнин | ________________А.В. Песошин |
| **М.У.** | **М.У.** |